# Татарстан Республикасының
# Урман кодексы

Урман - географик ландшафтның үсеш чорында үзара биологик бәйләнештә булган һәм бер-берсенә даими йогынты ясап торучы җир, агач, куак һәм башка үсемлекләр, җанварлар, микроорганизмнар һәм әйләнә-тирә мохитнең башка компонентлары җыелмасын тәшкил итүче элементы ул.

Әлеге Кодекс Татарстан Республикасында урманнардан нәтиҗәле файдалану, аларны яңадан торгызу, саклау һәм яклау максатларында урман фондын биләү, аның белән эш итү һәм файдалану вакытында килеп туган мөнәсәбәтләрне (алга таба - урман мөнәсәбәтләрен) җайга сала.

## 1 бүлек

## Гомуми нигезләмәләр

### <u>1 статья.</u> Татарстан Республикасында урман мөнәсәбәтләрен җайга салу

Татарстан Республикасында урман мөнәсәбәтләре Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Кодекс, шуңа нигезләнеп кабул ителгән башка закон актлары, "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында ике якка да караган эшләрне чикләү һәм вәкаләтләрне тапшырышу турында"гы Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе Шартнамәсендә билгеләнгән мәсьәләләр һәм Россия Федерациясенең урман турындагы законнарына таянып, районнарның дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының үз

24



вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән карарлары тарафыннан җайга салына.

Сулардан, җир асты байлыкларыннан, үсемлекләр (урманнан башка) һәм хайваннар дөньясыннан, атмосфера һавасыннан файдалану һәм аларны саклау рәвешендә урман фондыннан файдалануга кагылышлы мөнәсәбәтләр Татарстан Республикасының тиешле законнары тарафыннан җайга салына.

2 статья. Урманнар - халык байлыгы

Татарстан Республикасы территориясендә үсә торган урманнар республика халкының байлыгы булып тора.

Татарстан халкы исеменнән урманнарны биләү, алардан файдалану һәм аларга хуҗа булу хокукы Татарстан Республикасы Югары Советына бирелә, ул урманнарга хуҗа булуны республика Хөкүмәтенә яисә шуңа вәкаләтле махсус органнарга тапшыра ала, шулай ук "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында ике якка да караган эшләрне чикләү һәм вәкаләтләрне тапшырышу турында"гы Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе Шартнамәсе нигезендә кайбер мәсьәләләрне уртак хәл итү өчен Россия Федерациясенең хакимият һәм идарә органнарына тапшырырга мөмкин.

3 статья. Татарстан Республикасының урман фонды

Барлык урманнар, шулай ук урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру өчен бирелә торган урман белән капланмаган җирләр Татарстан

Республикасының урман фондын тәшкил итә.

Авыл хуҗалыгы һәм башка категория җирләрендәге мәйданы бер гектардан да ким булмаган табигый һәм утыртылган агачлыклар урман фондын тәшкил итә.

Урман фонды җирләренә түбәндәгеләр керә:

- урман җирләре - урман белән капланган җирләр һәм шулай ук урман белән капланмаган, ләкин урманны яңадан торгызу өчен билгеләнгән җирләр (киселгән урманнар, янган урманнар, ачыклыклар һәм башкалар);

- урман хуҗалыгы ихтыяҗларында файдаланыла торган урмансыз җирләр (печәнлекләр, сөрүлекләр, юллар, урман ызаннары һәм башкалар).

<u>4 статья.</u> Урман фондына керми торган агач һәм куак үсемлекләр

Урман фондына түбәндәгеләр керми:

- кыр ышыклау һәм яр буе полосалары агач төркемнәре, шулай ук авыл хуҗалыгы һәм башка категория җирләрендәге мәйданы бер гектардан ким булган табигый һәм утыртылган агач һәм куак үсемлекләр;

- тимер юл һәм автомобиль юлларын саклау өчен бүлеп бирелгән полосаларда утыртылган агачлыклар;

- шәһәрләрнең һәм башка торак урыннарының шәһәр урманнарына кермәгән җирләрендә үсә торган яшеллек өчен утыртылган агачлыклар һәм агач төркемнәре;

- йорт тирәсендәге, дача һәм бакча биләмәләрендәге агачлар һәм агач төркемнәре.

245



әлеге агачлыкларны утырту, аларны карау, алардан файдалану һәм аларны саклау, Татарстан Республикасы законнарында башкасы билгеләнмәгән булса, халык депутатларының район (шәһәр) Советлары билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5 статья. Урман мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә Татарстан хакимияте һәм идарәсенең республика органнары вәкаләтләре

Урман мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә Татарстан хакимияте һәм идарәсенең республика органнарына түбәндәге вәкаләтләр карый:

1) республиканың урман турындагы законнарын эшләү һәм камилләштерү;

2) республика территориясендәге урман фондына хуҗа булу;

3) урманны төркемнәргә һәм саклаучан категорияләргә бүлү һәм аларны бер төркемнән яки саклаучан категориядән икенчесенә күчерү;

4) урманнан файдаланган өчен түләү алу тәртибен һәм күләмен, аренда хакын, шулай ук түләүләр буенча ташламалар бирү тәртибен, урманны яңадан торгызу һәм саклау өчен республика бюджетыннан тыш фонд оештыру һәм аны файдалану;

5) урман фонды биләмәләрен арендага бирү тәртибен һәм аренда шартларын билгеләү;

6) урман фондыннан файдалану нормаларын һәм кагыйдәләрен билгеләү, еллык агач кисү нормасын (алдан хисапланган урман кисү күләмен) һәм урманнан файдалануның башка нормативларын раслау, үсеп утырган урманны сатып җибәрү, урман кисү, урман-

нарны яңадан торгызу, саклау һәм яклау кагыйдәләрен раслау;

7) урман хуҗалыгы буенча проектлау-конструкторлык, фәнни-тикшеренү эшләрен оештыру;

8) җирле үзидарә органнары белән берлектә, башка табигать саклау гамәлләре белән берраттән, урман фондын нәтиҗәле файдалану, аның файдалылыгын арттыру, урманны яңадан торгызу, саклау һәм яклау буенча Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү һәм аларның үтәлешен оештыру;

9) алдан хисапланган урман кисү күләме чикләрендә, дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итүне дә исәпкә алып, һәр район саен урман кисү фондының чикләрен билгеләү;

10) урманның халәтен, файдаланылышын, яңадан торгызылышын, сакланышын һәм якланышын дәүләт тарафыннан тикшереп тору;

11) урман фондының дәүләт исәбен, дәүләт урман кадастрын, урман мониторингын, урман төзелешен һәм урман хуҗалыгын проектлау эшләрен алып бару;

12) урман хуҗалыгы өлкәсендә халыкара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру.

6 статья. Урман мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының гамәлгә ашыра торган уртак мәсьәләләре

Урман мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасындагы вәкаләтләрне уртак гамәлгә ашыру мәсьәләләре "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте

органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында ике якка да караган эшләрне чикләү һәм вәкаләтләрне тапшырышу турында"гы Шартнамә нигезендә хәл ителәләр.

7 статья. Урман мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә халык депутатларының район (шәһәр) Советлары вәкаләтләре

Урман мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә халык депутатларының район (шәһәр) Советлары түбәндәге вәкаләтләргә ия:

1) урман хуҗалыгы үсеше программаларын эшләүдә һәм үтәүдә катнашу;

2) урман фондыннан файдалану тәртибен, урман кисү күләмнәрен, урманнан файдалануның башка нормативларын килештерү;

3) урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган максатларда урман фонды җирләрен тартып алу һәм бирү турындагы карарларны килештерү;

4) урманнардан файдаланган өчен түләү күләмнәрен һәм ставкаларын, урман фондыннан файдаланган өчен аренда хакы күләмнәрен билгеләү үзенчәлекләрен килештерү;

5) урман байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр буенча файдаланучыларның кайбер категорияләренә ташламалар бирү;

6) урман хуҗалыгы органнары белән берлектә урман фонды биләмәләрен озак вакытлы файдалануга (арендага) бирү турында карар кабул итү;

7) урманнардан файдалануны, аларны яңадан торгызуны, саклауны һәм яклауны тикшереп тору;

8) билгеләнгән тәртиптә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә ур-

ман фондыннан файдалануны чикләү, вакытлыча туктатып тору яисә бөтенләй туктату.

8 статья. Урман мөнәсәбәтләрен җайга салу әлкәсендә район (шәһәр) хакимиятләренең вәкаләтләре

Урман мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә район (шәһәр) хакимиятләренең вәкаләтләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) урман фондының исәбен алып бару;

2) расланган лимит чикләрендә урман кисү фондын бүлү;

3) урманнан файдаланган өчен һәм аренда өчен түләүләрне билгеләнгән тәртиптә җыюны тәэмин итү;

4) урманнарны яңадан торгызу, аларны янгыннан саклау, корткычлардан һәм урман авыруларыннан яклау гамәлләрен үтәүне оештыру;

5) әйләнә-тирә табигый мохитне саклау буенча махсус вәкаләтле органнар белән берлектә урманнардан файдалануны, аларны яңадан торгызуны, саклауны һәм яклауны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

6) урман фондын биләүчеләр белән берлектә урман фонды биләмәләрен кыска вакытлы файдалануга тапшыру турында карар кабул итү;

7) урманнан өстәмә файдалану мәсьәләләрен җайга салу;

8) билгеләнгән тәртиптә һәм үз вәкаләтләре чикләрендә урман фондыннан файдалану хокукын чикләү, аны туктатып тору яисә бөтенләй туктату.

9 статья. Урманнардан файдалану, аларны яңадан торгызу, саклау һәм яклау елкәсендә дәүләт идарәсе

Татарстан Республикасы территориясендә урманнардан файдалану, аларны яңадан торгызу, саклау һәм яклау өлкәсендә дәүләт идарәсе Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм урман хуҗалыгы идарәсенең махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Урман хуҗалыгы идарәсенең махсус вәкаләтле дәүләт органнары системасына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасының урман хуҗалыгы идарәсе дәүләт органы (Урман хуҗалыгы министрлыгы) һәм аның карамагындагы урман хуҗалыклары (лесхозлар), урманчылыклар һәм милли табигать парклары хакимиятләре.

Республика урман хуҗалыгы идарәсе дәүләт органының эшчәнлеге Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан расланучы нигезләмә белән билгеләнә.

Урман хуҗалыгы идарәсе дәүләт органнарының законнарда билгеләнгән чикләрдәге күрсәтмәләре, урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру кагыйдәләре һәм кулланмалары барлык урман фондын биләүчеләр, урман байлыкларыннан файдаланучылар, шулай ук урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру һәм урманнардан файдалануга бәйле булмаган эшләрне башкаручы хокукый һәм физик затлар өчен дә зарур.

<u>10 статья.</u> Урманнарның халәтен, файдаланылышын, аларның яңадан торгызылышын, сакланышын һәм якланышын дәүләт тарафыннан тикшереп тору

Урманнарның халәтен, янадан торгызылуын, алардан файдалануны, аларны саклау һәм яклауны дәүләт тарафыннан тикшереп тору максаты барлык урман фондын биләүчеләрнең, урманнан файдаланучыларның урман фондыннан файдалану буенча билгеләнгән тәртибен, урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру, урманнарны яңадан торгызау, саклау һәм яклау кагыйдәләрен, дәүләт исәбен алып бару, дәүләтнең хисап бирүе һәм урман турындагы законнарда каралган башка нормаларны һәм кагыйдәләрне үтәлүләрен тәэмин итүдән гыйбарәт.

Урманнарның халәтен, яңадан торгызылуын, саклануын һәм яклануын дәүләт тарафыннан тикшереп торуны Татарстан Республикасы Югары Советы, халык депутатларының район (шәһәр) Советлары, урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары һәм әйләнә-тирә табигый мохитне саклауның дәүләт органнары гамәлгә ашыра.

Урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары тарафыннан урманнарның халәтен, файдаланылуын, яңадан торгызылуын, саклануын һәм яклануын дәүләт тарафыннан тикшереп тору тәртибен Татарстан Республикасы Хөкүмәте билгели.

<u>11 статья.</u> Урман фондын биләү

Татарстан Республикасы урман фонды урман хуҗалыгын гамәлгә ашыручы урман хуҗалыклары, милли табигать парклары, тыюлыклар, колхоз, совхозлар һәм башка авыл хуҗалыгы берләшмәләренең

биләмәсе булып тора.

Колхозлар элек үзләренә чикләнмәгән вакытка файдалануга тапшырылган җирләрдәге урман фондын биләүчеләр булып торалар, совхозлар һәм башка авыл хуҗалыгы берләшмәләре биләвендә аларга элек беркетелгән урман фонды була.

<u>12 статья.</u> Урман фондын биләүчеләрнең вазыйфалары

Урман фондын биләүчеләрнең вазыйфалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) урман фонды җирләрен билгеләнгән максатта файдалануны тәэмин итү, аларның уңдырышлылыгын арттыру һәм аларны саклау;

2) урманнарны яңадан торгызу һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру, аларны карау, урман фондыннан нәтиҗәле файдалануны оештыру;

3) урманны чистарту, карау, аның санитария хәлен яхшырту һәм яңадан торгызу максатында кисү;

4) урман фонды территориясендә янгынга каршы гамәлләр һәм санитария гамәлләре уздыру, урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозуны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау, янгыннарны вакытында табу һәм сүндерү эшләрен оештыру, урманнарны корткычлардан, авырулардан саклау һәм аларга каршы көрәш;

5) урман фондын кисү өчен әзерләү һәм урман кисү билетлары (ордерлары) бирү;

6) урманнан файдаланучылар башкара торган эшләрне тикшереп тору, урман фондыннан файдалану нормаларын һәм кагыйдәләрен бозуны, шулай ук урманда аны файдалану белән бәйле булмаган эшләр башкаруны, законсыз урман кисүләрне булдырмау, агач

һәм куакларны, яшь үсентеләрне, урман культураларын зарарлауны һәм аларны юк итүне тыю, урманнарны химик, радиоактив матдәләр, шакшы сулар, коммуналь-көнкүреш калдыклары һәм ташландыклары белән пычратуларга һәм урман турындагы законнарны башкача бозуларга юл куймау;

7) халык депутатларының район (шәһәр) Советларының урман хуҗалыгы идарәсе органы карары нигезендә, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау һәм табигый байлыклар министрлыгының төбәк комитетлары белән килешеп, урман фонды биләмәләрен озак вакытлы файдалануга (арендага) тапшыру;

8) хокукый һәм физик затларга урманнан файдалану, урманда башка хуҗалык эшләре башкару өчен хокук бирү һәм моның өчен кирәкле биләмәләр бүлеп бирү;

9) район хакимиятләре карарлары нигезендә урманнарда янгын сүндерү өчен урманнан файдаланучыларның махсуслаштырылган хезмәтләрен һәм халыкны җәлеп итү;

10) урман фондының исәбен алып бару;

11) хайваннар дөньясын саклау һәм, әйләнә-тирә мохитне саклауның дәүләт органнары белән үзара килешеп, урман фондындагы кыргый җәнлекләрнең җитәрлек санын һәм аларны аулау нормасын билгеләү.

Урман фондын биләүчеләр урманнан файдалану хокукына ия, шулай ук аларга юллар, складлар, янгынга каршы корылмалар, торак һәм хуҗалык биналары, үсентеләр үстерү урыннары һәм урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка объектлар төзү рөхсәт ителә, алар урманнан файдаланучылар хокукларыннан файдаланалар һәм үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны үтиләр.

## II бүлек

## Урман хуҗалыгын оештыру

<u>13 статья.</u> Урман хуҗалыгын гамәлгә ашыруның төп таләпләре

Урман хуҗалыгы гамәлләре һәм урман фондыннан файдалану әйләнә-тирә табигый мохиткә һәм кешенең сәламәтлегенә зыян китерми торган ысуллар белән хәзерге һәм киләчәк буыннарның мәнфәгатьләрен исәпкә алып гамәлгә ашырылырга тиеш.

Урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- кешенең сәламәтлеген саклау мәнфәгатьләрендә урманнарның уңай мохит хасил итү үзенчәлекләрен, су саклау, ышыклау, санитария-гигиена, савыктыру һәм башка файдалы табигый үзенчәлекләрен саклау һәм арттыру;

- халык хуҗалыгы һәм гражданнарның үзагачка һәм башка урман продукциясенә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен урман фондыннан һәр төрле максатларда, өзлексез һәм аны юкка сарыф итмичә файдалану;

- урманны яңадан торгызу, аның токым составын һәм сыйфатын яхшырту, нәтиҗәлелеген арттыру, аны сакчыл тоту, саклау һәм яклау;

- урман фонды җирләреннән нәтиҗәле файдалану;

- бердәм техник сәясәт, фән, техника һәм алдынгы тәҗрибә куллану нигезендә урман хуҗалыгын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру;

- биологик күптөрлелекне, тарихи-мәдәни һәм табигый мирас

объектларын саклап калу;

- ау җәнлекләрен яңадан үрчетү өчен уңай шартлар тудыру максатында биотехник гамәлләр җыелмасын башкару.

14 статья. Урман хуҗалыгын оештыру нигезләре

Урман хуҗалыгын оештыру аны гамәлгә ашыруны һәм урман байлыкларыннан файдалануны хокукый һәм техник яктан җайга салуны тәэмин итәргә тиеш һәм ул түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- урман фондын әлеге Кодексның 15-19 статьяларында каралган төркемнәргә һәм саклanучан категорияләргә кертү;

- хуҗалыклар төзү (ылыслылар, каты яфраклылар, йомшак яфраклылар һ.б. буенча);

- хуҗалык секцияләре төзү (нәтиҗәлелеге, максатка ярашлылыгы һәм башка үзенчәлекләре буенча);

- урманны кисү елларын һәм кисү әйләнешләрен билгеләү;

- урман байлыкларыннан файдалану нормаларын билгеләү;

- урманны кисү һәм урман байлыкларын яңадан торгызу системасын урнаштыру;

- урманнарны саклау һәм яклау, урман фонды җирләрен саклау гамәлләре системасын билгеләү;

- башка техник-оештыру һәм хокукый гамәлләр.

15 статья. Урман фондын урман төркемнәренә һәм саклanучан категорияләргә бүлү

Урман фонды халык хуҗалыгында тоткан роле һәм экологик әһәмияте, урнашкан җире һәм үтәгән вазыйфалары буенча урман

төркемнәренә һәм саклanучан категорияләргә бүленә.

Татарстан Республикасында урман фонды беренче һәм икенче урман төркемнәренә карый, беренче урман төркеме саклanучан категорияләргә керә.

16 статья. Беренче төркем урманнар

Беренче төркем урманнарга саклanучан категориядәге башлыча түбәндәге вазыйфаларны үтәүче урманнар керә:

- су саклаучы урманнар - елгалар, күлләр, сусаклагычлар һәм башка су объектлары ярлары буендагы тыюлык полосалары, кыйммәтле балыкларның уылдык чәчү урыннарын саклаучы тыюлык урман полосалары;

- саклаучы (ышыклаучы) урманнар - эрозиягә каршы урманнар, тимер юл, федераль һәм республика автомобиль юллары буендагы ышыклау урман полосалары, дала, урманлы дала һәм аз урманлы районнарда әйләнә-тирә мохитне саклау өчен аеруча әһәмияткә ия булган башка урманнар;

- санитария-гигиена һәм савыктыру урманнары - шәһәр урманнары, урман-парклар, шәһәр, башка торак пунктлары, сәнәгать предприятиеләре тирәсендәге яшел зона урманнары, су чыганакларын санитар саклау зоналарындагы беренче һәм икенче пояс урманнары, шифаханәләрне санитар саклау округларының беренче, икенче, өченче зона урманнары;

- махсус саклanылучы территориялардәге урманнар - аеруча кыйммәтле урман массивлары, фәнни һәм тарихи әһәмияткә ия булган урманнар, табигать ядкярләре;

- табигый тыюлык фонды урманнары - тыюлыклар, тыюлы урман

биләмәләре, милли табигать парклары.

17 статья. Икенче төркем урманнар

Икенче төркем урманнарга мохитне саклауда әһәмияткә ия булган, ышыклау һәм урманнан файдалануны чикләү вазыйфаларын үтәүче һәм шулай ук урман байлыклары җитәрлек булмаган районнардагы урманнар керә, аларны саклау вазыйфаларын тәэмин итү йөзеннән, урман фондыннан файдалану чикләнгән режимда алып барыла.

18 статья. Һәр төркем һәм һәр сакланучан категория урманнары биләгән җирләрнең чикләрен билгеләү

Урман фондын урман төркемнәренә һәм сакланучан категорияләргә кертү белән бергә, һәр төркем һәм һәр сакланучан категория биләгән җирләрнең чикләре билгеләнә.

Һәр төркем урманнарда файдалану режимы чикләнгән махсус сакланучан урман биләмәләре ачыкланырга мөмкин - урмансыз территория белән чиктәш урман авызы, сирәк очрый торган яки югалып баручы кыргый җәнлекләр һәм үсемлекләрнең яшәү, таралу урыннары, елга, күл, үзән, ерганак буйларындагы яр саклагыч урман биләмәләре һәм башкалар.

19 статья. Урман фондын төркемнәргә һәм саклануучан категорияләргә бүлү тәртибе һәм махсус саклануучан урман биләмәләрен ачыклау

Урман фондын төркемнәргә һәм саклануучан категорияләргә кертү һәм шулай ук аларны бер төркемнән икенчесенә күчерү урман хуҗалыгын оештыру материаллары нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә башкарыла.

Файдалану режимы чикләнгән махсус сакланылучы урман биләмәләрен урман хуҗалыгын оештыру материаллары яисә әйләнә-тирә мохитне саклауның дәүләт органнары белән килешенгән республика урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары тарафыннан махсус тикшеренүләр нигезендә ачыклана һәм бу биләмәләрне Татарстан Республикасы Хөкүмәте раслый.

Урманнарның төркеменә, саклануучан категориясенә карап, аларда урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру, урман фондыннан файдалану тәртибе, шулай ук урман фонды җирләрен дәүләт һәм җәмгать ихтыяҗлары өчен алу тәртибе билгеләнә.

20 статья. Урманны кисү елларын һәм кисү әйләнешен билгеләү тәртибе

Урманны кисү еллары һәм кисү әйләнеше аның билгеләнгән төп максатыннан һәм үтәгән экологик, икътисадый һәм җәмгыяви вазыйфаларыннан, урманның нәтиҗәлелегеннән һәм анда үсүче үзагач токымнарының биологик үзенчәлекләреннән, шулай ук киселгән урманнарны торгызу вакытыннан чыгып билгеләнә.

Урманны кисү елларын һәм кисү әйләнешен урман хуҗалыгын

258

оештырганда яисә махсус фәнни тикшеренүләр нәтиҗәсендә нигезләнә.

Урманны кисү елларын һәм кисү әйләнешен республика урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органы билгели.

21 статья. Алдан хисапланган урман кисү күләме һәм аны раслау тәртибе

Алдан хисапланган урман кисү күләме, төп файдаланылучы урманны һәр урман фондын биләүче буенча (урман хуҗалыгы, колхоз, совхоз, башка авыл хуҗалыгы берләшмәсе) озак вакытлы кисүнең планлы нормативы буларак, урман төзелешен билгеләгәндә урман хуҗалыклары, урман төркемнәре, саклнучан категорияләр һәм хуҗалыклар өчен (ылыслы, каты яфраклы һәм йомшак яфраклы), урман фондыннан эзлексез файдалану һәм аны ярлыландырмау үзенчәлекләреннән чыгып, аерым-аерым исәпләнелә.

Урман хуҗалыгын гамәлгә ашыручы оешманың урман фонды ике яисә берничә район территориясендә урнашкан очракта алдан хисапланган урман кисү күләме һәр район буенча билгеләнә.

Алдан хисапланган урман кисү күләмен раслауга тәкъдим ителгән исәп-хисап һәм нигезләүче материаллар, тәкъдимнәр республика Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан, халык депутатларының район (шәһәр) Советлары, әйләнә-тирә мохитне саклауның дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасының Икътисад һәм күзаллау буенча дәүләт комитеты белән килешенеп, әзерләнә һәм раслауга тәкъдим ителә.

Алдан хисапланган урман кисү күләме урман хуҗалыгын оештыру эшләре тәмамланганнан соңгы елның 1 гыйнварена раслана

һәм гамәлгә кертелә.

Республика буенча алдан хисапланган урман кисү күләме барлык урман хуҗалыклары, колхозлар, совхозлар һәм башка авыл хуҗалыгы берләшмәләре өчен билгеләнгән тәртиптә хисапланган урман кисү күләменең суммасы буларак билгеләнә.

Урман фондының чикләре, урманны кисү еллары, урман төркемнәре һәм саклanучан категорияләр үзгәргәндә яисә урман фондында башка үзгәрешләр булганда, алдан хисапланган урман кисү күләме билгеләнгән тәртиптә яңадан каралып, расланырга мөмкин.

22 статья. Урман фондын урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру һәм урманнан файдалану белән бәйле булмаган максатларда җирләрнең башка категорияләренә күчерү тәртибе

Урман фонды җирләрен урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру һәм урманнан файдалану белән бәйле булмаган максатларда җирләрнең башка категорияләренә күчерү тәртибе Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Беренче төркем урманнардагы урман җирләрен урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган максатларда куллану өчен урмансыз төркемнәргә бары тик гадәттән тыш очракларда гына күчерелә.

Беренче һәм икенче төркем урман җирләре биләмәләрен урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган максатларда куллану өчен, биләмәләрнең мәйданына һәм төренә карамастан, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карары нигезендә генә тартып алына һәм бүлеп бирелә.

Урман фонды җирләрен урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган максатларда башка категорияле җирләргә күчереп бүлеп алганда яисә вакытлыча биләгәндә, шулай ук урман фондын биләүчеләрнең һәм аннан файдаланучыларның хокукларын чикләгәндә яисә хокукый яки физик затның эшчәнлеге нәтиҗәсендә җирләр начарланганда, Татарстан Республикасы Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә әлеге затлар китерелгән зыянны һәм урман хуҗалыгындагы югалтуларны кайтаралар.

<u>23 статья.</u> Урман җирләрен урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру белән бәйле максатларда урмансыз җирләргә күчерү тәртибе

Урман җирләре урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру белән бәйле максатларда файдалану өчен республика Урман хуҗалыгы министрлыгы рөхсәте белән урмансыз җирләргә күчерелә.

<u>24 статья.</u> Төзелеш объектлары проектларын һәм урыннарын, урманнарда урман хуҗалыгын гамәлгә ашыруга бәйле булмаган эшләр башкаруны килештерү тәртибе

Урманнарның халәтенә һәм аларны яңадан торгызуга тәэсир итә торган төзелеш объектларының проектлары һәм аларның урыннары, шулай ук урманнарда урман хуҗалыгын гамәлгә ашыруга бәйләнешсез эшләр башкару район (шәһәр) хакимиятләре, урман хуҗалыклары, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый байлыкларның дәүләт органнары белән килешенеп хәл ителә.

## Ш бүлек

## Урманнан файдалану

25 статья. Урман байлыклары һәм урманнан файдалану

Урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру вакытында барлыкка килә торган, кешенең матди һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кулланыла торган агач материаллары, техник, дару, төрлек азыгы, азык-төлек продуктлары, урманның саклау һәм сәламәтлек өчен файдалы өлешләре урман байлыкларын тәшкил итә.

Урманнан файдалану (урман байлыкларыннан файдалану) килешү шартларында яки әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә урман фондын биләүчеләрнең бер тапкырга гына яраклы рөхсәте нигезендә гамәлгә ашырыла.

26 статья. Урман фондыннан файдалану төрләре һәм вакыты

Билгеләнгән таләпләрне һәм шартларны үтәгәндә урман фондыннан түбәндәгечә файдаланырга мөмкин:

1) агач (үзагач) әзерләү;

2) агач сагызы әзерләү;

3) иярчен агач материаллары әзерләү (агач тепләре, сүссыман өлешләре, кайры, каен тузы, төрле агач ботаклары);

4) урманнан өстәмә файдалану (җиләк-җимеш, чикләвек, гөмбә, агач сулары һәм башка ашамлык азыклары, дару үләннәре һәм техник чимал, печән әзерләү һәм җыю, умарталар һәм умарталыклар урнаштыру);

5) урман фондыннан мәдәни һәм савыктыру максатларында файдалану;

6) урман фондыннан аучылык хуҗалыгы ихтыяҗларында файдалану;

7) урман фондыннан фәнни-тикшеренү максатларында файдалану.

Урман фонды биләмәләре кыска вакытлы файдалануга - бер елга кадәр яисә озак вакытлы файдалануга (арендага) - илле елга кадәр бирелергә мөмкин. Озак вакытлы файдалануга бирелгән урман фонды биләмәсе, файдалану вакыты узганчы, файдаланучылар инициативасы нигезендә билгеләнгән тәртиптә озайтылырга мөмкин.

<u>27 статья.</u> Урманнан файдаланучылар

Татарстан Республикасы законнары нигезендә урман фондыннан файдалануны гамәлгә ашыру хокукына ия булган хокукый затлар, шул исәптән чит ил затлары һәм физик затлар Татарстан Республикасында урманнан файдаланучылар булалар.

<u>28 статья.</u> Урман байлыкларын файдалануга тапшыру тәртибе

Урманнан файдалану, әлеге Кодексның 37 статьясында каралганнардан гайре, махсус рөхсәт нигезендә генә гамәлгә ашырыла.

Урман байлыклары махсус рөхсәт документлары - лицензия, урман кисү билеты (ордеры), урман билеты нигезендә файдалануга тапшырыла.

Лицензия - аның иясенең урман фонды биләмәсеннән озак ва-

кытлы файдалану хокукына ия булуын раслаучы документ.

Урман кисү билеты (ордеры) һәм урман билеты - аларның ияләренең урман байлыкларыннан кыска вакытлы файдалану хокукына ия булуын раслаучы документ. Урман кисү билеты (ордеры) һәм урман билеты аларның ияләренең урманның фәкать әлеге документларда күрсәтелгән төрләреннән генә файдаланырга хаклы икәнен раслый.

Урманнан файдалану җирле халыкның мәнфәгатьләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

29 статья. Урман фонды биләмәләрен арендалау

Урман фонды биләмәләрен озак вакытлы файдалануга аренда рәвешендә тапшыру халык депутатларының район (шәһәр) Советы һәм урман хуҗалыгы идарәсе дәүләт органы - урман хуҗалыгы карары нигезендә башкарыла.

Татарстан Республикасында урман фонды биләмәләре арендага - мәдәни- савыктыру, фәнни-тикшеренү максатларында файдалану өчен, аучылык хуҗалыгы ихтыяҗлары һәм башка төрле өстәмә файдаланулар өчен тапшырыла.

Урман фонды биләмәләре арендага лицензия нигезендә тапшырыла.

Урман фонды биләмәләрен субарендага тапшыру тыела.

Урман фондын арендага алучылар урманнан файдаланучыларның барлык хокукларына ия, алар урманнан файдалану тәртибен һәм үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны үтәргә тиеш.

Урман фондын арендалау турындагы нигезләмә Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан раслана.

30 статья. Урман фондыннан файдалану лицензиясе

Лицензиядә, аңа теркәлгән килешүләр белән бергә, түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелергә тиеш:

- урман фонды биләмәсе чикләренең тасвирламасы;

- урманнан файдалануның төрләре, күләмнәре һәм тәртибе, арендалау вакыты;

- урманнан файдаланучының һәм арендага бирүченең урман байлыкларын саклау, яклау һәм яңадан торгызу буенча бурычлары, урман хуҗалыгы гамәлләрен финанслау шартлары һәм тәртибе;

- аренда хакы күләме һәм аны түләү вакыты;

- урман фондының тасвирламасы һәм лицензия вакыты тәмамланганда урман фонды халәтенә куела торган таләпләр.

Лицензия урман фондыннан файдаланганда әлеге Кодекска каршы килми торган башка шартлар белән тулыландырылырга мөмкин.

Лицензия халык депутатларының район (шәһәр) Советларының әйләнә-тирә табигый мохитне саклау органнары белән килешенгән карары нигезендә урман хуҗалыгы идарәсе органнары тарафыннан бирелә.

31 статья. Урман кисү билеты (ордеры) һәм урман билеты

Урман кисү билеты - аның иясенә, сагыз, иярчен агач материаллары әзерләү һәм урманнан ташу хокукын бирә торган документ. Урман кисү билетында җибәрелгән агачның, сагызның һәм иярчен агач материалларының күләм һәм сыйфат тасвирламасы, аларның хакы, эшне башкару вакыты, урманны яңадан торгызу һәм

кисү урыннарын чистарту шартлары күрсәтелә. Урман кисү билеты урман хуҗалыгы, шулай ук хокукый зат статусына ия булган урманчылык тарафыннан бирелә.

Үсеп утырган (тамырдагы) урманны ваклап бүлеп кисү һәм ташу өчен бирелә торган ордер - аның иясенә агач һәм иярчен урман материалларын әзерләүгә һәм ташуга хокук бирүче документ. Ордер урманчылык тарафыннан язылган урман кисү билеты нигезендә бирелә. Ауган, корыган һәм сынган агачларны җыю, шулай ук иярчен агач материалларын әзерләү өчен ордер алу урман кисү билеты язып бирмичә дә рөхсәт ителергә мөмкин.

Урман билеты - иясенә урманнан кыска вакытлы файдалануга рөхсәт бирүче документ. Анда урман фондыннан файдалануның урыны, күләмнәре, вакыты, урманнан өстәмә файдалануларның шартлары һәм түләү хакының күләме күрсәтелә. Урман билеты урманнан өстәмә файдалану өчен урманчылык тарафыннан бер сезонга бирелә.

Урманнан файдаланганда урман фондын биләүчеләр файдалану хокукын гомуми нигезләрдә рәсмиләштерергә тиешләр.

32 статья. Урманнан файдаланучыларның хокуклары

Урманнан файдаланучылар түбәндәге хокукларга ия:

- файдалануның төренә карап, билгеләнгән вакытта агач, сагыз, иярчен агач материаллары әзерләү өчен, шулай ук урманнан өстәмә файдалану һәм башка максатлар өчен урман фонды биләмәләре алу;

- файдалануның төренә карап, билгеләнгән тәртиптә юллар

салырга, урман продукциясен туплау өчен аерым мәйданнар кору, вакытлыча файдалану өчен җитештерү һәм хуҗалык корылмалары салу, транспорт тукталышлары булдыру, урыннарын урман хуҗалыклары белән килешеп, урманнан файдалану өчен кирәкле җиһазлар һәм җайланмалар кору.

Урманнан файдаланучыларның бозылган хокуклары яңадан торгызыла. Урманнан файдаланучыларга китерелгән зыян кире кайтарыла. Бозылган хокукларны һәм китерелгән зыянны каплау турындагы бәхәсләр судта яки арбитраж судта карала.

Урман фонды җирләрен дәүләт һәм җәмгатьчелек ихтыяҗлары өчен алган очракта урманнан файдаланучыларга килгән турыдан-туры зыян тулысынча кире кайтарыла.

<u>33 статья.</u> Урманнан файдаланучыларның бурычлары

Урманнан фйдаланучыларның бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- урманнан файдалану эшләрен туфрак эрозиясен барлыкка китермәслек, урманнан файдалануның урманның торышына һәм яңадан торгызылуына, шулай ук сулыклар һәм башка табигать объектларына тискәре йогынтысын чикләрлек яки бөтенләй булдырмый торган ысуллар белән алып бару;

- янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү, эш урыннарында янгынга каршы гамәлләр уздыру, ә янгын чыккан очракта аларны сүндерү;

- кисү өчен бүлеп бирелгән урман фондын, сагыз яисә агач суы җыю өчен бирелгән агачлыкларны, шулай ук печәнлекләрне һәм

файдалануга бирелгән башка урман байлыкларын тулысынча һәм нәтиҗәле куллану;

- киселергә билгеләнгән агачларны кисеп бетермичә калдырмау, кисү һәм урманнан чыгу вакыты уагач, әзерләнгән агачны урманда калдырмау;

- файдалану нәтиҗәсендә зарарланган урман фонды биләмәләрен үз хисабына билгеләнгән максатларда файдалануга яраклы хәлгә һәм рөхсәт документларында күрсәтелгән хәлгә китерү;

- кисү урыннарын үз вакытында урман кисү калдыкларыннан чистарту;

- эшләр тәмамлангач, урман фонды биләмәләрен биләүчеләренә тапшыру;

- урман киселгән урыннарда һәм башка мәйданнарда рөхсәт документларында күрсәтелгән шартларда һәм вакытта урманны яңадан торгызу гамәлләрен башкару. Урманнан файдалану нәтиҗәсендә урман киселгән урыннарда һәм башка мәйданнарда яшь агачлар яки урман юк ителгән булса, урманны яңадан торгызу эшләрен үз хисабына башкару;

- лицензиядә каралган шартларны үтәү;

- урман фондыннан файдаланган өчен түләүләрне үз вакытында һәм билгеләнгән тәртиптә кертү;

- урманнарда санитария кагыйдәләрен үтәү, урман фондыннан файдалану тәртибен җайга салучы башка кагыйдәләрне үтәү, шулай ук урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары, әйләнә-тирә табигый мохитне саклауның дәүләт органнары урындагы затларының үз вәкаләтләре чикләрендә бирелгән күрсәтмәләрен үтәү;

- урман фондыннан файдалану хакында рөхсәт документлары биргән органнарга билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат бирү.

34 статья. Урманнан файдалану хокукларын туктату сәбәпләре

Урманнан файдалану хокукы түбәндәге очракларда туктатыла:

1) рөхсәт документларында күрсәтелгән файдалану вакыты тәмамланганда;

2) урманнан файдаланучы үз хокукларыннан баш тартканда;

3) урманнан рөхсәт документларында каралганча файдалануның алга таба гамәлгә ашырылуына юл калдырмый торган шартлар килеп туганда.

Урманнан файдаланучының хокукы урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары тәкъдиме белән урман фондын файдалануга бирү турында карар кабул иткән хакимият органы тарафыннан түбәндәге очракларда вакытыннан элек туктатылырга мөмкин:

1) гадәттән тыш хәл (табигый бәла-казалар) килеп чыкканда;

2) урманнан файдаланучы даими рәвештә (ике тапкырдан артык) билгеләнгән файдалану кагыйдәләрен бозып, урман фондына шактый зыян китергәндә;

3) урманнан файдаланучылар рөхсәт документларында күрсәтелгән вакытта файдалануга керешмәгәндә;

4) урман фонды биләмәләре файдалануга бирелгән предприятие яки башка хуҗалык итүче субъект ябылганда;

5) урманнан файдалану өчен түләү даими рәвештә кертелмәгәндә;

6) лицензияләрне, урман кисү билетын (ордерын) яки урман билетын урман фондыннан файдалану кагыйдәләрен бозып биргәндә;

7) файдаланучы гаебе белән урманда янгын чыкканда һәм таралганда;

8) рөхсәт документларында каралган максатларга яраксыз

рәвештә урманнан файдаланганда.

35 статья. Урманнан файдалану хокукын туктату тәртибе

Урманнан файдалану хокукын туктату лицензияне, урман кисү билетын (ордерын), урман билетын биргән органнар тарафыннан әлеге рөхсәт документларын гамәлдән чыгару юлы белән хәл ителә.

Урманнан файдаланучы урманнан файдалану хокукын туктату яки чикләү турындагы карар белән килешмәсә, судка яисә арбитраж судка шикаять бирә ала.

36 статья. Урман фондыннан файдалану хокукын туктатып тору һәм чикләү сәбәпләре

Урман фондыннан файдалану хокукы рөхсәт документлары биргән орган тарафыннан түбәндәге очракларда туктатып торылырга яки чикләнергә мөмкин:

- урманнан файдаланучының рөхсәт документларында каралган шартларны бозганда;

- урманнан файдалану өчен билгеләнгән вакытта түләмәгәндә;

- урманнан файдаланучы гаебе белән урманнарның санитария һәм экология халәте начарайганда.

Әгәр урманнан файдаланучының хокукын чикләүгә яисә туктатып торуга сәбәпче хәлләр яки шартлар юкка чыгарылса, бу хокук тулысынча яңадан кайтарылырга мөмкин.

Урманнан файдаланучы үзенең хокукын чикләү яки туктатып

тору турындагы карар белән килешмәсә, судка яисә арбитраж судка шикаять бирә ала.

37 статья. Гражданнарның урманнарда булулары

Гражданнар ял итү, шәхси файдалану өчен җиләк-җимеш, чикләвек, гөмбә, урмандагы башка ашамлык продуктлары, дару үләннәре, техник чимал җыю, мәдәни һәм савыктыру гамәлләрендә, турист һәм спорт гамәлләрендә катнашу максатларында урманнарга керә алалар.

Гражданнар урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәргә, урман культураларына зыян китермәскә, агач һәм куакларны сындырмаска, урманнарны чүпләмәскә, кырмыска өемнәрен, кош ояларын туздырмаска тиешләр, шулай ук җиләк-җимеш, чикләвек, үләннәрне аларның яңадан үсүенә зыян китерми торган ысуллар белән һәм үз вакытында гына җыярга тиеш.

Гражданнарның урманнарда йөрүләре, җиләк-җимеш, чикләвек, гөмбә, башка ашамлык продуктлары, дару үләннәре, техник чимал җыюлары янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, урман орлыкчылыгы хуҗалыгын алып бару ихтыяҗларында Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә чикләнергә мөмкин, ә тыюлык урманнарына, милли табигый паркларга һәм башка махсус саклану территорияләргә керү тәртибе аларда урманнан файдалануның билгеләнгән режимы нигезендә чикләнергә мөмкин.

38 статья. Урман кисү төрләре

Урманнарда агач әзерләү түбәндәге тәртиптә алып барыла:

- төп файдалану урманнарын кисү - җитлеккән һәм артык җитлеккән агачлыкларны билгеләнгән тәртиптә тоташ кисү;

- арадаш файдалану урманнарын кисү - урманны карау гамәлләре тәртибендә кисү, санитария халәтен яхшырту өчен кисү, аз кыйммәтле һәм ышыклау, су саклау, табигатьне саклау буенча башка вазыйфаларын югалта баручы агачлыкларны алмаштыру өчен кисү;

- башка төр кисүләр - бүлеп алынган урман мәйданнарын чистартканда, урманнарда юл ярганда, янгынга каршы зермалар салганда һәм башка шундый очракларда кисү.

39 статья. Төрле төркем һәм саклanучан категория урманнарында урман кисү төрләре һәм ысуллары

Икенче төркем урманнарда төп файдалану урманнарын кисү аны хуҗалык өчен кыйммәтле агач токымнары исәбенә яңадан торгызуга, бу урманнарның табигатьне саклау вазыйфаларын тәэмин итүгә һәм шул ук вакытта аларны нәтиҗәле, нигезле файдалануга юнәлдерелгән ысуллар белән башкарыла.

Беренче төркем урманнарда төп файдалану урманнарын кисү агачлыкларның халәтен яхшыртуга, аларның ышыклау, су (дым) саклау һәм башка файдалы табигый сыйфатларын көчәйтүгә, шулай ук җитлеккән һәм артык җитлеккән агач запасларын үз вакытында һәм нәтиҗәле файдалануга юнәлдерелә.

Милли табигый паркларда, фәнни һәм тарихи әһәмияткә ия һәм табигать ядкярләре булган урманнарда, урман-паркларда, яшел зоналарның урман-парк өлешенә кергән, су белән тәэмин итү чыганакларының санитария саклавы зоналарының беренче һәм икен-

че поясы, шифаханәләрнең санитария саклавы округларының беренче, икенче зона урманнарында, эрозиягә каршы урманнарда, зеруча кыйммәтле урман массивларында һәм кыйммәтле балыкларның уылдык чәчү урыннарын саклаучы урман полосаларында, урманны карау чарасы буларак, аның санитария халәтен яхшырту максатында кисү һәм аз кыйммәтле, ышыклау, су (дым) саклау һәм башка экологик вазыйфаларын югалта баручы агачлыкларны алмаштыру тәртибендә кисү үткәрелә; шулай ук урман мәйданнарын бина һәм корылма төзү урыннары өчен чистарту, янгынга каршы аермалар, юллар, ачыклыклар яру һәм башка шундый урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру максатларында үзгә кисүләр башкарыла.

Тыюлык урманнарында, тыюлык урман биләмәләрендә бары тик тыюлыкның эшчәнлеге белән бәйле булган максатларда гына урман кисү рөхсәт ителә.

Махсус сакланучан урман биләмәләрендә тоташ кисү бөтенләй яки өлешчә тыелырга мөмин, ә аерым очракларда төп файдалану урманнарын кисүнең башка ысулларын куллану да тыелырга мөмкин. Кисүләрне тыю турындагы карар җирле үзидарәнең район органнары тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органы тарафыннан кабул ителә.

40 статья. Агач әзерләү тәртибе

Төп файдалану һәм арадаш файдалану урманнарын кисү Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы раслаган кагыйдәләр (кулланмалар) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман кисү фондын бүлеп бирү һәм урманнан файдаланучыларга тапшыру, шулай ук агач әзерләү тәртибе Татарстан Республи-

касы урманнарында тамырдагы агачны сатып җибәрү хакындагы Татарстан Республикасы Хөкүмәте раслаган кагыйдәләр нигезендә билгеләнә.

## 41 статья. Төп файдалану урманнарын кискәндә агач әзерләү күләмен билгеләү

Төп файдалану урманнарын кискәндә агач әзерләү һәр урман фондын биләүчегә хисапланган урман кисү күләмендә гамәлгә ашырыла. Алдан хисапланган урман кисү күләменнән артык агач әзерләү тыела.

Урман кисү фондын төп файдалану урманнарын кискәндә агач әзерләү өчен билгеләнгән җитлеккән һәм артык җитлеккән агачлыклар хасил итә. Һәр төркем урман чикләрендә агач әзерләүчеләргә ел саен бүлеп бирелә торган урман кисү фондының күләме әлеге Кодекста каралган тәртиптә билгеләнә.

## 42 статья. Арадаш файдалану урманнарын кискәндә агач әзерләү күләмен билгеләү

Арадаш файдалану урманнарын кискәндә агач әзерләү күләме урман хуҗалыгын оештыру материаллары нигезендә урманны карау, аның санитария халәтен яхшырту һәм үсентеләрен алмаштыру нормаларыннан чыгып исәпләнелә, ә башка төр кисүләр барышында агач әзерләү күләме урман биләмәләрен төзелеш объектлары өчен, ачыклыклар яру һәм башка шундый максатлар өчен чистарту эшләре күләмендә билгеләнә.

43 статья. Агач сагызы әзерләү тәртибе

Агач сагызы әзерләү җитлеккән һәм артык җитлеккән ылыслы агачлыкларда үткәрелә - әзерләү вакыты уагач, алар кисү өчен билгеләнә. Сагыз әзерләү өчен җитлеккән һәм артык җитлеккән агачлыклар җитәрлек булмаганда, җитлегеп килүче агачлыкларны файдалану да рөхсәт ителә. Сагыз чыгару чоры тәмамлануга, алар кисү яшенә җитәчәк һәм киселү өчен әзер булачак.

Кисү һәм сагыз җыю планын расламый торып, әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән агачлыкларны сагыз әзерләү өчен бирү тыела.

Агачлыкларда сагыз әзерләү кагыйдәләрен, шулай ук аларның сагыз әзерләү мәҗбүри булган зоналарын Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы раслый.

44 статья. Урман фондын иярчен агач материаллары әзерләү өчен файдалану һәм урманнан өстәмә файдалануларны гамәлгә ашыру тәртибе

Урман фондын иярчен агач материаллары әзерләү йөзеннән файдалану өчен, хокукый һәм физик затларның аннан өстәмә файдалануларын гамәлгә ашыру өчен әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә бирелә.

Урман фондын иярчен агач материаллары әзерләү өчен файдалану һәм өстәмә файдалану кагыйдәләре Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан раслана.

45 статья. Урман фондын мәдәни һәм савыктыру максатларында файдалану тәртибе

Район (шәһәр) хакимияте, урман фондын биләүчеләр һәм алар белән килешенеп урманнан файдаланучылар урманнарда халыкның ял итүен оештыру максатында яшел зоналарда, ял итү өчен файдаланыла торган башка урман фонды биләмәләрендә төзекләндерү һәм халыкка мәдәни, көнкүреш хезмәте күрсәтү гамәлләре үткәрәләр, бу очракта, урман мохитен һәм табигать ландшафтларын саклау зарурияten исәпкә алып, шәһәр тирәсе зоналарының архитектура планнары таләпләре, янгынга каршы һәм санитария кагыйдәләре үтәлергә тиеш.

Урман фондын мәдәни һәм савыктыру максатларында файдалану тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы Хөкүмәте раслаган кагыйдәләр нигезендә җайга салына.

46 статья. Урман фондыннан фәнни-тикшеренү максатларында файдалану тәртибе

Фәнни-тикшеренү эшләре алып бару өчен фәнни учреждениеләргә, оешмаларга урман фондыннан махсус биләмәләр бүлеп бирелергә мөмкин. Башка хокукый һәм физик затларның бүлеп бирелгән биләмәләрдән фәнни-тикшеренү эшләре максатларына каршы килә торган файдаланулары өлешчә яки бөтенләй тыела.

Урман фондыннан фәнни-тикшеренү максатларында файдалану тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

**47 статья.** Урман фондыннан аучылык хуҗалыгы ихтыяҗларында файдалану тәртибе

Аучылык хуҗалыгы ихтыяҗларында файдалану өчен махсус аучылык хуҗалыкларына, җәмәгать аучылык оешмаларына, башка хокукый затларга әлеге Кодекста күрсәтелгән тәртиптә урман фонды бирелә.

Урман фондыннан файдалану һәм урман хуҗалыгында үткәрелә торган гамәлләр кыргый җанварларның яшәеше өчен уңай шартларны саклау зарурияттен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Ау җәнлекләрен аулау саны билгеләнгән нормативлардан артып китсә, урман фондын аучылык хуҗалыгы ихтыяҗларында файдаланучылар урман хуҗалыгына килгән зыян өчен җаваплы булалар.

Җәнлекләрнең зеруча зиннәтле төрләре яши торган урманнарда агач әзерләү бары тик әйләнә-тирә табигый мохитне саклауның дәүләт органнары белән килешеп гамәлгә ашырыла. Урманда җәнлекләрнең сирәк очрый һәм югалып бара торган төрләренең яшәү мохитенә һәлакәт куркынычы тудыручы яисә аның начарлануына китерүче агач әзерләүләр рөхсәт ителми.

Урман фондын аучылык хуҗалыгы ихтыяҗларында файдалану тәртибе һәм шартлары Урманнан аучылык хуҗалыгы ихтыяҗларында файдалану турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте раслаган кагыйдәләр нигезендә билгеләнә.

<u>48 статья.</u> Тыюлык урманнарында һәм милли табигый паркларда урман фондыннан файдалану

Тыюлык урманнарында һәм милли табигый паркларда аларның вазыйфаларына каршы килә торган урман фондыннан файдаланулар тыела.

<u>49 статья.</u> Колхозлар, совхозлар, башка авыл хуҗалыгы берләшмәләре урманнарында урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру һәм урманнан файдалану үзенчәлекләре

Колхозлар, совхозлар һәм башка авыл хуҗалыгы берләшмәләрен урманнарында урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру һәм урман фондыннан файдалану аларның агачка һәм башка урман продуктларына булган ихтыяҗларын тәэмин итү йөзеннән башкарыла.

Колхозлар, совхозлар, башка авыл хуҗалыгы берләшмәләре үзләре карамагындагы урман фондында урман хуҗалыгын гамәлгә ашыруны хуҗалыкара урман хуҗалыклары аша урман хуҗалыгының дәүләт органнары белән төзелгән шартнамәләр нигезендә әлеге Кодекска, колхозлар, совхозлар, башка авыл хуҗалыгы берләшмәләре урманнарында урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру турындагы Татарстан Республикасы Хөкүмәте раслаган нигезләмәгә туры китереп оештырырга тиеш.

Колхозлар, совхозлар, башка авыл хуҗалыгы берләшмәләре урманнарында урман байлыкларының халәтен, яңадан торгызылуын, сакланышын һәм якланышын, файдаланылуын дәүләт тарафыннан тикшереп торуны халык депутатлары Советлары, урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары һәм әйләнә-тирә табигый мохитне сак-

лауның дәүләт органнары гамәлгә ашыра.

Колхозлар, совхозлар, башка авыл хуҗалыгы берләшмәләре урман хуҗалыгын гамәлгә ашыруның Татарстан Республикасы Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләрен һәм нормаларын даими рәвештә бозган өчен урман фондын биләү хокукыннан мәхрүм ителергә һәм алар карамагындагы урман фонды урман хуҗалыгы идарәсенен дәүләт органнарына тапшырылырга мөмкин.

Колхозлар, совхозлар һәм башка авыл хуҗалыгы берләшмәләре урманнарында урман байлыкларын куллану өчен урман кисү билеты (ордеры) һәм урман билеты урман хуҗалыгын гамәлгә ашыручы орган (оешма) тарафыннан бирелә.

## 1У бүлек

## Урманнарны яңадан торгызу һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру. Урманнарны саклау һәм яклау

50 статья. Урманнарның нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын арттыру буенча урман фондын биләүчеләрнең бурычлары

Урман фондын биләүчеләр урманнарның сыйфатын яхшырту, аларның нәтиҗәлелеген һәм мохитне саклау вазыйфаларын арттыру буенча түбәндәге бурычларны үтәргә тиешләр:

- урманнарны даими карап тору, хуҗалык өчен әеруча кыйммәтле агач токымнарының, селекция, орлыкчылык, сортларны сынау эшләрен алып бару, туфракның уңдырышлылыгын күтәрү, туфракта эрозия, сазлану һәм аның сыйфатын начарлата торган башка тис-

кәре күренешләрне булдырмый калу;

- урман фонды җирләрендә, билгеләнгән мәйданнарда урманнарны яңадан торгызу һәм яңаларын утырту юлы белән аларның тулы һәм нәтиҗәле файдаланылышы буенча гамәлләр кабул итү;

- урманнарның токым составын, сыйфатын яхшырту, аларның нәтиҗәлелеген һәм саклау үзенчәлекләрен арттыруга юнәлдерелгән башка гамәлләрне башкару.

51 статья. Урман орлыкчылыгы эше

Урман хуҗалыгы предприятиеләре, урманнарның нәтиҗәлелеген арттыру йөзеннән, урман орлыкчылыгы базасын булдыру, агач токымнарының кыйммәтле генетик фондын ачыклау, ишәйтү һәм саклап калу эшләрен башкарырга тиеш.

Агач токымнарының генетик фондын саклау һәм файдалану тәртибе Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы раслаган нигезләмә белән җайга салына.

52 статья. Урманнарны яңадан торгызу тәртибе

Урманнарны яңадан торгызу, агач орлыкларын әзерләү һәм утырту өчен үсентеләр үстерү эшләрен урман фондын биләүчеләр дә, урманнан файдаланучылар да гамәлгә ашыра. Урман белән капланмаган мәйданнарда урманнарны яңадан торгызу урман культураларын утырту яки аларның табигый яңарылышына булышлык итү гамәлләре үткәрү юлы белән тормышка ашырыла.

Урманнарны яңадан торгызу ысуллары агач токымнарының үсү урыны шартлары һәм урманчылык үзенчәлекләреннән чыгып билгелә-

нә. Алар кыска вакыт эчендә хуҗалык өчен кыйммәтле агач токымнарыннан торган һәм нәтиҗәлелеге югары булган урманнар булдыруны тәэмин итәргә тиеш. Урманны яңадан торгызу эшләренең күләмнәре, утыртыла торган һәм табигый яңарылышка калдырыла торган мәйданнарның чагыштырмасы урман хуҗалыгы төгәлеше эшләрен башкарганда билгеләнә һәм аңа, урман фондында бара торган үзгәрешләрне исәпкә алып, төзәтмәләр кертелә.

Киселгән җирләрдә һәм урман белән капланмаган башка мәйданнарда урман утырту һәм аның өчен үсентеләр үстерү тәртибе һәм чоры Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

<u>53 статья.</u> Урманны яңадан торгызу өчен уңай шартларны саклап калуда урманнан файдаланучыларның бурычлары

Урманнан файдаланучылар аны яңадан торгызу өчен уңай шартларны саклап калу таләпләрен үтәргә тиеш. Бу таләпләр агач һәм башка урман байлыкларын әзерләү һәм ташу өчен яңа техника эшләгәндә исәпкә алынырга тиеш.

Урман фондын биләүчеләр файдалануга биргән урман биләмәләрендә файдаланучыларның башкарган эшләре урманнарны яңадан торгызуга тискәре йогынты ясаса, урманчылык таләпләренең бозылу сәбәпләрен бетергәнгә кадәр ул эшләрне туктатып тора алалар.

Урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары урман әзерләүчеләрдән киселгән җирләрдә урманны яңадан торгызу өчен уңай шартларны саклау чыгымнарын каплауны тәэмин итәрлек күләмдә

акча алалар.

54 статья. Урман утырту эшләрен башкару тәртибе

Территорияләрдә урманнарны арттыру һәм эрозия күренешләрен булдырмау, экологик хәлне яхшырту максатында ерганак, чокыр, комлык, шулай ук ашалган, файдалану өчен уңайсыз булган авыл хуҗалыгы җирләрендә һәм кайбер башка җирләрдә урман утыртыла.

Урман утырту эшләре урман хуҗалыгы, авыл хуҗалыгы, әйләнә-тирә табигый мохитне саклауның дәүләт органнары белән килешү буенча, дәүләт идарәсе һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган махсус программалар һәм проектлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман утырту эшләре җирдән файдаланучыларга йөкләнә, шулай ук алар урман хуҗалыгы предприятиеләре белән төзелгән шартнамәләр нигезендә үтәлергә мөмкин.

55 статья. Урманнарны саклауның һәм яклауның максатлары һәм бурычлары

Барлык урманнар янгыннардан, законсыз кисүләрдән, урманнан файдалануның билгеләнгән тәртибен бозулардан, урманга зыян китерерлек башка гамәлләрдән, шулай ук корткычлардан һәм авырулардан сакланырга тиеш.

Урманнарны саклау һәм яклау урман фондының биологик һәм төбәк үзенчәлекләрен исәпкә алып, аны нәтиҗәле файдалануга, юк ителүдән, бозылудан, зәгыйфьләнүдән, пычранудан һәм башка тис-

282

кәре йогынтыдан саклауга юнәлдерелгән оештыру, икътисадый, хокукый һәм башка гамәлләр җыелмасын үз эченә ала.

56 статья. Урманнарны саклау һәм яклау гамәлләрен башкару тәртибе

Татарстан Республикасы Хөкүмәте, район хакимиятләре урман хуҗалыгы идарәсе органнары аша урманнарны саклау һәм яклау гамәлләрен, корткычларга һәм урман авыруларына, янгыннарга каршы көрәшнен үтәлешен тәэмин итәләр, янгын сүндерү өчен халыкны, янгын сүндерү техникасын, транспорт чараларын, предприятие һәм оешмалар хезмәткәрләрен җәлеп итәләр; кирәк очракларда, янгын куркынычы көчәйгән чорда, халыкның урманда йөрүен, урманга транспорт чаралары керүне, шулай ук урман фондының аерым биләмәләрендә кайбер эшләр башкаруны тыялар.

57 статья. Колхозлар, совхозлар, башка авыл хуҗалыгы берләшмәләре урманнарында һәм тыюлык урманнарында урман үсентеләрен саклау һәм яклау

Колхозлар, совхозлар, башка авыл хуҗалыгы берләшмәләре урманнарын, тыюлык урманнарын янгыннан, законсыз кисүләрдән, корткычлардан һәм авырулардан саклау өчен ведомство урман саклавы оештырыла. Ведомство урман саклавы турындагы нигезләмә урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органы, әйләнә-тирә табигый мохитне саклауның дәүләт органы һәм Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан раслана.

Әлеге урманнарны авиация ярдәмендә саклау урман хуҗалыгы

идарәсе дәүләт органының урманнарны саклау базалары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

58 статья. Урман фондына кермәүче агач һәм куак үсемлекләрен саклау һәм яклау

Кыр ышыклау урман полосаларын, тимер юл һәм автомобиль юллары буена утыртылган урман фондына кермәүче ышыклау агачлыкларын саклау һәм яклау җирдән файдаланучылар, тиешле министрлыклар, дәүләт комитетлары, ведомстволар һәм халык депутатларының район (шәһәр) Советлары тарафыннан тәэмин ителә.

59 статья. Урманда янгыннарга, корткычларга һәм урман авыруларына каршы көрәштә дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләре

Татарстан Республикасы Хөкүмәте, район хакимиятләре, урманнарда янгыннар булдырмый калу, янгыннарга, корткычларга һәм урман авыруларына каршы көрәш йөзеннән, түбәндәге гамәлләрне башкаралар:

- ел саен урманнарны саклау һәм яклау вазыйфалары йөкләнгән предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм урманнан файдаланучылар тарафыннан янгыннарны кисәтү, янгынга каршы җиһазлар һәм җайланмалар булдыру, күрсәтелгән предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның янгын куркынычы арткан сезонга әзерлек чараларын эшләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыралар;

- ел саен янгын куркынычы арткан сезон башланганчы, ур-

маннарда янгынга каршы көрәшнең кичектергесез планнарын раслыйлар;

- җирле халыкны, эшче һәм хезмәткәрләрне, шулай ук предприятие, учреждение, оешмаларның янгын сүндерү техникасын, транспорт чараларын һәм башка чараларны урман янгыннарын сүндерү өчен җәлеп итү тәртибен билгелиләр; бу эшкә тартылган кешеләрне транспорт белән, азык-төлек белән тәэмин итүнең, аларга медицина ярдәме күрсәтүнең тәртибен билгелиләр;

- урманнарда янгын куркынычы көчәеп киткән чорда янгын сүндерүгә җәлеп ителгән кешеләр һәм транспорт чаралары ярдәме белән янгын сүндерү бүлекчәләре оештыруны һәм урманда кинәт янгын чыккан очракта аларның кичекмәстән янгын урынына килеп җитү әзерлеген тәэмин итәләр;

- янгынга каршы көрәш өчен юллар салуда, урманны саклау өчен кулланылучы самолетлар һәм вертолетлар өчен аэродромнар һәм аларның төшүе өчен мәйданчыклар төзүдә, ягулык һәм майлау материаллары ташып куюда булышлык күрсәтәләр, шулай ук янгын куркынычы көчәйгән чорда урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары карамагына кизү транспорты сыйфатында кирәк кадәр автомобиль һәм башка транспорт чаралары бирәләр;

- янгынга каршы киң пропаганда алып баруны, урманнарны саклау, урманда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү мәсьәләләрен матбугатта һәм телевидение аша даими яктыртып торуны оештыралар;

- территорияләрдә урман янгыннары белән көрәш буенча барлык гамәлләрнең тәртипкә салынуын тәэмин итәләр, кирәк очракларда бу максатларда махсус комиссияләр оештыралар.

60 статья. Эшчәнлекләре урманнарның халәтенә һәм яңадан торгызылуына йогынты ясый торган предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның бурычлары

Эшчәнлекләре урманнарның халәтенә һәм яңадан торгызылуына йогынты ясый торган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, дәүләт урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары, әйләнә-тирә табигый мохитне саклауның дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары белән килешеп, урманнарны янгыннардан саклауга юнәлдерелгән технологик санитария һәм башка гамәлләр үткәрергә бурычлы.

61 статья. Татарстан Республикасының дәүләт урман саклавы хезмәте

Татарстан Республикасының дәүләт урман саклавы хезмәте урманнарны файдалану, яңадан торгызу, саклау һәм яклау гамәлләрен тормышка ашыру максатларында урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары системасында оештырыла.

Дәүләт урман саклавы хезмәтенә урман законнарын бозуларны кисәтү һәм тыю хокукы бирелә.

Дәүләт урман саклавы хезмәткәрләре законда билгеләнгән тәртиптә урындагы җитәкче затларга һәм гражданнарга урман законнарын бозган өчен административ штраф салырга, урман хуҗалыгына китерелгән зыянны кайтару өчен судка һәм арбитраж судка шикаять белдерергә хаклы.

Дәүләт урман саклавы хезмәтендә эшләүчеләр урманнарны

яңадан торгызу һәм саклау өчен бюджеттан тыш дәүләт фонды хисабына шәхесләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүенә хаклы.

Дәүләт урман саклавы хезмәткәрләренең исемлеге Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органы тарафыннан раслана.

Дәүләт урман саклавы хезмәте эшчәнлеге Татарстан Республикасы Хөкүмәте раслаган нигезләмә тарафыннан җайга салына.

62 статья. Гражданнарның һәм җәмәгать берләшмәләренең урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә катнашуы

Гражданнар һәм җәмәгать берләшмәләре Татарстан Республикасы законнарында каралган тәртиптә урманнарның нәтиҗәле файдаланылуын, торгызылуын, сакланышын һәм якланышын тәэмин итү эшчәнлегендә катнаша алалар.

## У б ү л е к

## Урман фондыннан файдалану өчен түләүләр һәм урман хуҗалыгын финанслау

63 статья. Урманнан файдалануның түләүле булуы

Урманнан файдалану, әлеге Кодексның 37 статьясында каралган очраклардан тыш, түләүле була.

Урманнан файдаланган өчен түләүләрдән түбәндәгеләр азат ителәләр:

- урман фондыннан урман хуҗалыгын гамәлгә ашыру максатында файдаланучы урман фондын биләүчеләр (урманнарны карау, чистарту һәм санитария халәтен яхшырту максатында һәм башка урман хуҗалыгы гамәлләрен үткәргәндә киселгән агачлар өчен, иярчен агач материаллары әзерләү һәм урманнан өстәмә файдалану өчен);

- урман фондыннан фәнни-тикшеренү максатларында файдаланучы фәнни-тикшеренү оешмалары һәм уку йортлары.

Халык депутатларының район (шәһәр) Советлары урманнан файдаланучыларның кайбер категорияләренә ташлама ясарга яисә урман фондыннан файдалану өчен түләүләрдән бөтенләй азат ителергә мөмкин.

64 статья. Түләү төрләре

Урманнан файдалану өчен түләү системасы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- урман байлыкларыннан файдаланган өчен түләү;

- аренда түләве;

- урманнарны яңадан торгызу, саклау һәм яклау фондына күчерелә торган түләүләр.

65 статья. Урман байлыклары өчен түләү

Түләүләр урман байлыкларыннан түбәндәгечә файдаланган өчен алына:

- үсеп утырган (тамырдагы) урманны кисәргә биргән өчен;

- сагыз һәм иярчен агач материалларын әзерләгән өчен;

- агач суларын, җиләк-җимеш, гөмбә, дару үләннәрен, тех-

ник чималны төп кәсеп сыйфатында егерләгән өчен, умарталар һәм умарталыклар урнаштырган, печән чапкан өчен һәм урманнан өстәмә файдалануның башка төрләре өчен;

- урман фондыннан мәдәни һәм савыктыру максатларында файдаланган өчен;

- урман фондыннан аучылык хуҗалыгы ихтыяҗларында файдаланган өчен.

Урман фонды җирләре өчен түләүләр Татарстан Республикасының "Җир өчен түләү турында" Законы нигезендә алына.

66 статья. Аренда түләве

Урман фонды биләмәләрен арендага биргән өчен аренда түләве алына.

Аренда түләве күләме урман фонды биләмәләренең микъдарына, сыйфатына һәм урнашкан урынына карап билгеләнә.

Урман фонды биләмәләрен арендалау өчен түләү күләмен һәм ставкаларын билгеләү тәртибе һәм түләүне кертү вакыты Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

67 статья. Урман байлыклары өчен түләү хакы, күләме һәм түләү шартлары

Урманнан файдаланучылар (арендаторлардан тыш) урман фондыннан файдалану хокукы гамәлдә булу дәверендә бер тапкыр яисә даими рәвештә урман байлыклары өчен түлиләр.

Түләү хаклары урманнан файдаланганда алынган продукция берәмлеге өчен билгеләнгән ставкалардан чыгып исәпләнә, ә ур-

ман фондыннан файдалануның кайбер төрләре буенча урман фонды биләмәсенең һәр гектарына куелган бәясенә карап билгеләнә.

Урман байлыклары өчен түләү күләмен һәм ставкаларын ачыклау тәртибен Татарстан Республикасы Хөкүмәте билгели.

68 статья. Урманнан файдалану өчен түләүнең бүленеше

Урман байлыклары һәм аренда өчен түләүләр территорияләрендә урманнан файдалану гамәлгә ашырыла торган районнарның (шәһәрләрнең) бюджетларына кертелә.

Халык депутатларының район (шәһәр) Советлары карары белән бу түләүләрнең бер өлеше урманнарны саклауга һәм яклауга тотыла.

69 статья. Урманнарны яңадан торгызу, саклау һәм яклау өчен түләүләр

Барлык урманнан файдаланучылар үзләре әзерләгән, саткан, эшкәрткән, шулай ук үз ихтыяҗларында файдаланган агач өчен, сату бәяләреннән чыгып алынган агач хакы проценты күләмендә урманны яңадан торгызу, саклау һәм яклау өчен түләүләр кертәләр.

Барлык бу түләүләр урманнан файдаланучы әзерләгән продукциянең үзкыйммәтенә кертелә һәм урманны яңадан торгызу, саклау һәм яклау фондында туплана.

Урманнарны яңадан торгызу, саклау һәм яклау өчен түләүләрнең күләме, аны алу, бүлү һәм файдалану тәртибе урманнарны торгызу, саклау һәм яклау буенча Татарстан Республикасы Югары

290

Советы раслаган Бюджеттан тыш дәүләт фонды турындагы нигезләмә тарафыннан билгеләнә.

70 статья. Урман хуҗалыгын финанслау

Урманнарны яңадан торгызу, саклау, яклау, урманны карау эшләрен, урман фондыннан файдалануны оештыру, урман хуҗалыгын оештыру эшләрен һәм урманнарның исәбен, мониторингын, фәнни-тикшеренү, проектлау-конструкторлык эшләрен алып бару, дәүләт урман саклавы хезмәтен тоту, урман хуҗалыгы предприятиеләренең матди-техник базасын ныгыту һәм урман поселокларының җәмгаяви үсешен финанслау чыганаклары республика бюджетыннан шул максатлар өчен бүлеп бирелгән, шулай ук урманнарны яңадан торгызу, саклау һәм яклау буенча бюджеттан тыш дәүләт фонды акчаларыннан гыйбарәт.

## У1 б ү л е к

## Урман хуҗалыгын оештыру эшләрен башкару, дәүләт урман кадастры һәм урман фондының дәүләт исәбен алу. Урман мониторингы

71 статья. Урман хуҗалыгын оештыру эшләре

Урман хуҗалыгын оештыру эшләре урманнарны нәтиҗәле файдалану, аларның файдалылыгын арттыру, яңадан торгызу, саклау һәм яклау, урман хуҗалыгында бердәм фәнни һәм техник сәясәт алып

баруга юнәлдерелгән гамәлләр системасын үз эченә ала.

Урман хуҗалыгын оештыру эшләре вакытында түбәндәгеләр башкарыла:

- урман хуҗалыгы, колхоз, совхоз, башка авыл хуҗалыгы берләшмәләре, тиюлыклар карамагындагы урман фондының чикләрен ачыклау һәм алар территориясендәге эчке хуҗалык эшләрен оештыру;

- топография - геодезия эшләрен башкару һәм урманнарның махсус картасын төзү;

- агачлыкларның токым һәм яшь составын, аларның халәтен ачыклап, шулай ук урман байлыкларының сыйфатын һәм микъдарын билгеләп, урман фондын барлап чыгу;

- төп файдалану урманнарын кисәргә, арадаш файдалану өчен һәм хуҗалык ягыннан әһәмияте аз булган агачлыкларны алмаштыру максатында кисәргә яраклы биләмәләрне ачыклау, урманнарны яңадан торгызу, яңадан утырту, сугару, саклау һәм яклау, башка хуҗалык гамәлләре башкару, шулай ук аларны уздыру тәртибен һәм ысулларын билгеләү;

- урманнарны төркемнәргә һәм саклanучан категорияләргә кертүне нигезләү һәм аларны бер төркемнән, категориядән икенчесенә күчерү буенча тәкъдимнәр кертү;

- төп файдалану урманнарын кисү буенча алдан хисапланган урман кисү күләмен, урманнарны карау рәвешендә чистарту өчен кисү, хуҗалык вазыйфаларын югалтып баручы агачлыкларны алмаштыру максатында кисү һәм башка төр файдалануларның күләмен билгеләү;

- урманнарны яңадан торгызу, яңадан утырту, янгыннардан, корткычлардан, урман авыруларыннан саклау гамәлләренең күлә-

мен, шулай ук башка урман хуҗалыгы эшләренең күләмен ачыклау;

- урманнардан өстәмә файдалану күләмен, иярчен агач материаллары әзерләү күләмен, урман фондыннан аучылык хуҗалыгы ихтыяҗларында һәм мәдәни-савыктыру йөзеннән файдалану күләмен ачыклау;

- урманда биологик, башка төр эзләнү һәм тикшеренү эшләре үткәрү;

- урман хуҗалыгын оештыру һәм алып бару проектларының гамәлгә ашырылуына авторлык күзәтүе, шулай ук башка урман хуҗалыгын оештыру эшләре башкару.

<u>72 статья.</u> Урман хуҗалыгын оештыру материаллары буенча төзелгән проектлар

Урман хуҗалыгын оештыру эшләрен башкарганда урман фондын биләүчеләр өчен проектлар төзелә, аларда узган чорда урман хуҗалыгын гамәлгә ашыруга һәм урманнан файдалануга төрле яклап һәм тулаем бәя бирелә, урман хуҗалыгын оештыруның һәм үстерүнең төп нигезләмәләре эшләнелә. Әлеге проектлар һәм урман хуҗалыгын оештыруның башка материаллары, җирле үзидарә һәм әйләнә-тирә табигый мохитне саклауның дәүләт органнары белән, ә колхозлар, совхозлар, башка авыл хуҗалыгы берләшмәләре урманнары өчен авыл хуҗалыгы органнары белән килешенгәннән соң, урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары тарафыннан раслана һәм алга таба урман хуҗалыгын гамәлгә ашырганда, урманнан файдалануларны оештырганда, киләчәк һәм агымдагы планнарны фаразлаганда төп һәм мәҗбүри норматив-техник документ булып тора.

293

73 статья. Урман хуҗалыгын оештыру эшләрен үткәрү системасы

Татарстан Республикасы урманнарында урман хуҗалыгын оештыру эшләре, аның белән шөгыльләнүче махсус предпритиеләр тарафыннан бердәм система буенча, Татарстан Республикасының урман хуҗалыгы министрлыгы билгеләгән тәртиптә башкарыла.

74 статья. Дәүләт урман кадастры. Урман фондының дәүләт исәбе

Дәүләт урман кадастры һәм урман фондының дәүләт исәбе урман фондыннан нәтиҗәле файдалануны оештыру, урманнарны торгызу, саклау һәм яклау өчен, санын һәм сыйфатын даими тикшереп тору өчен һәм дәүләт органнарын, башка кызыксынган предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны һәм гражданнарны урман фонды турындагы мәгълүматлар (белдешмәләр) белән тәэмин итү өчен алып барыла.

Дәүләт урман кадастры һәм урман фондының дәүләт исәбе турындагы мәгълүматлар матбугатта игълан ителергә тиеш.

Дәүләт урман кадастры һәм урман фондының дәүләт исәбе урман фондының хокукый режимын, аның биләүчеләргә бүлеп бирелешен, сан һәм сыйфат халәтен, төркемнәргә һәм саклану категорияләргә бүленүе турындагы белешмәләрне, шулай ук аның икътисадый бәяләмәсен һәм урман хуҗалыгын алып бару һәм урманда хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен бәяләү өчен зарури булган башка мәгълүматлар системасын үз эченә ала.

Дәүләт урман кадастры һәм урман фондының дәүләт исәбе, урман хуҗалыгын оештыру материаллары, барлау һәм тикшеренүләр нигезендә, бердәм система буенча урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары тарафыннан башкарыла. Дәүләт урман кадастры һәм урман фондының дәүләт исәбе документларын үз биләвендә урман фонды булган барлык предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар алып бара.

75 статья. Урман мониторингы

Урман мониторингы, урманнан файдалану, аны яңадан торгызу, саклау, яклау һәм аның табигатьне саклау вазыйфаларын арттыру өлкәсендә нәтиҗәле идарәне гамәлгә ашыру йөзеннән, урман фондының халәтен бәяләү һәм фаразлау системасыннан гыйбарәт.

Урман мониторингының төзелеше (структурасы), асылы һәм гамәлгә ашырылу тәртибе Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары һәм әйләнә-тирә табигый мохитне саклауның дәүләт органнары белән берлектә билгеләнә.

УП бүлек

Урман турындагы бәхәсләрне хәл итү.
Урман турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

76 статья. Урман турындагы бәхәсләрне хәл итү тәртибе

Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар арасындагы урманнан файдалану, урман фонды биләмәләрен аренда-

лау һәм урманнардагы башка эшләр белән бәйле бәхәсләрне суд яки арбитраж суд хәл итә.

77 статья. Урман фондын биләүчеләрнең хокукын бозучы килешүләрнең гамәлгә яраксызлыгы

Урман фонды биләмәләрен үз белдеге белән сату, бүләк итү, әҗәткә бирү, рөхсәтсез алмашу, урманнан файдалану хокукын башкаларга тапшыру турындагы килешүләр төзелгән мизгелләреннән үк гамәлгә яраксыз була.

Урман фондыннан рөхсәтсез алынган биләмәләр, законсыз файдалану чорында тотылган чыгымнар һәм, законсыз төзелгән бина һәм корылмаларны сүтеп күчерү өчен тотылган чыгымнарны капламыйча, биләүчеләренә кире кайтарып бирелә.

78 статья. Урман турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

Әлеге Кодексның 77 статьясында каралган гамәлләрне кылган өчен һәм шулай ук түбәндәгеләр өчен гаепле затлар закон нигезендә җинаять җаваплылыгына, административ һәм башка җаваплылыкка тартылалар:

- рөхсәтсез агач кискән һәм зарарлаган өчен;

- ут төрткән, ут белән саксыз эш итү нәтиҗәсендә урманны юк иткән яки аңа зыян китергән өчен;

- урманнарда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәмәгән өчен һәм санитария кагыйдәләрен бозган өчен;

- урман фондын химик, радиоактив матдәләр белән пычраткан

өчен, аны производство калдыклары һәм шакшы сулар, коммуналь-көнкүреш калдыклары һәм ташландыклары белән пычраткан өчен;

- урман культураларын, чәчкеннәрне, урман питомникларындагы һәм плантацияләрендәге үсентеләрне, шулай ук урманны яңадан торгызу өчен билгеләнгән мәйданнардагы табигый үсмер агачларны һәм башка агачларны һәлак иткән яки зарарлаган өчен;

- урман кисү фондыннан файдалануның, агач әзерләү һәм чыгаруның, сагыз җыю һәм иярчен агач материаллары әзерләүнең билгеләнгән тәртибен бозган өчен;

- урманда печән чабу һәм мал көтү кагыйдәләрен бозган өчен, урман фондындагы печәнлек һәм көтүлек җирләрен зарарлаган өчен;

- җиләк-җимеш, гөмбә, дару үләннәре җыю тыелган яисә урман билетлары белән генә җыярга рөхсәт ителә торган биләмәләрдә аларны җыйган өчен, шулай ук аларны җыюның билгеләнгән вакытын бозган өчен;

- урман фонды җирләрен рөхсәтсез биләгән өчен;

- файдалануга алынган урман фонды биләмәләрен үз вакытында һәм алга таба билгеләнгәнчә файдаланырлык хәлгә китермәгән өчен;

- урман фонды җирләрендә рөхсәтсез агач төпләгән өчен, биналар, корылмалар төзегән өчен, складлар ясаган өчен, урман туфрагын һәм туфракның өске катламын рөхсәтсез бозган өчен;

- урманнан рөхсәтнамә документларында күрсәтелгән максатлар һәм таләпләр буенча файдаланмаган өчен;

- урман фонды җирләрендәге киптерү канауларын, дренаж системаларын һәм юлларын юк иткән яисә зарарлаган өчен;

- урман фондындагы чикләү тамгаларын, урман хуҗалыгына караган билгеләрне һәм башка билгеләрне юк иткән һәм зарарлаган өчен;

- урманның хайваннар дөньясын һәлак иткән өчен.

Татарстан Республикасы законнары нигезендә урман турындагы законнарны башкача бозулар өчен дә җаваплылык билгеләнергә мөмкин.

Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар урман турындагы законнарны бозу нәтиҗәсендә китерелгән зыянны кире кайтарырга тиеш.

Тиешле рөхсәт документларыннан тыш әзерләнгән агач һәм башка урман продукциясе, әлеге Кодексның 37 статьясында күрсәтелгән очраклардан гайре, гаеплеләрдән тартып алына һәм урман фонды биләүчеләре тарафыннан сатыла.

Урман хуҗалыгына килгән зыянны исәпләү һәм аның микъдарын ачыклау тәртибе Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

79 статья. Дәүләт урман фондына кермәүче ышыклау һәм яшелләндерү агачлыкларын һәм куакларын юк иткән яисә зарарлаган өчен җаваплылык

Урман фондына кермәүче кыр ышыклау урман полосалары, башка саклау, яшелләндерү максатларында утыртылган агачлыкларны һәм куаклыкларны юк итү яки зарарлауда гаепле затлар, әгәр аларның гамәлләре өчен тагын да катгыйрак җаваплылык каралмаган булса, урман фондының махсус саклаулы территорияләрендәге урманнарны юк иткән яки зарарлаган өчен билгеләнгән җаваплылыкка тартылалар.

80 статья. Урманнарның халәте һәм аларны яңадан торгызуга куркыныч тудыра торган гамәлләрне туктатып тору

Әгәр предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар яисә гражданнар урманнарда аларның халәтенә һәм яңадан торгызылуына тискәре йогынты ясаучы гамәлләр башкарсалар һәм шул ук вакытта урманнарны янгыннан саклауны тәэмин итмәсәләр, андый эшләргә сәбәпче булган шартларны бетергәнгә кадәр, урман хуҗалыгы идарәсенең дәүләт органнары һәм әйләнә-тирә табигый мохитне саклауның дәүләт органнары тәкъдиме белән, башкарма хакимият органнары тарафыннан ул гамәлләр вакытлыча туктатылырга яисә бөтенләй тыелырга мөмкин.

УШ бүлек

Халыкара шартнамәләр

81 статья. Халыкара шартнамәләр

Әгәр Татарстан Республикасы катнашучы шартнамәдә Урман кодексындагыдан үзгәрәк кагыйдәләр билгеләгән булса, ул вакытта халыкара шартнамәдәге кагыйдәләр кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 20 июле
№ 2194-XП